Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының

Борискино авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2022 ел № 55

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Борискино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районының Борискино авыл Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Борискино авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Әлмәт муниципаль районы Советы белән килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Борискино авыл Советы карарын гамәлдән чыгарырга:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның 14 октябрендәге 24 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның 20 декабрендәге 30 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл Советының 2021 елның 14 октябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 20 гыйнварындагы 32 номерлы;

4. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк ур., 61 йорт, Берёзовка бистәсе , Үзәк урам, 16 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Борискино
авыл җирлеге башлыгы Ж.С.Илалов